**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июнь № 438

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елның 1 июленнән хезмәт өчен түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары белән җайга салына торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә 1280,0 сум күләмдә өстәмә акча билгеләргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карамагындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмалары һәм дәүләт социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2012 ел, 10 декабрь, 1072 нче;

«Фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендә дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында» 2013 ел, 31 июль, 538 нче.

2. Әлеге өстәмә акча ай саен, бу чорда эшләнгән вакытка пропорциональ түләнә, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы оешмалар хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 19 октябрь, 870 нче; 2012 ел, 6 ноябрь, 966 нчы; 2013 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2013 ел, 31 декабрь, 1104 нче; 2014 ел, 16 октябрь,

762 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 812 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп (теркәлгән), үзгәреш кертергә.

4. Бу карарның көче хезмәтләре өчен түләүне арттыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 20 декабрь, 2291-б номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла торган дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә таралмый дип билгеләргә, «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеменә караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре хезмәткәрләреннән һәм мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләреннән гайре.

5. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында шундый ук карарлар кабул итергә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә эш хакын арттыру турында шундый ук карарлар кабул итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 14 июнь, 477 нче
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 27 июнь, 438 нче
карары редакциясендә)

Хезмәт өчен түләүләре Бердәм тариф челтәре нигезендә хисаплап чыгарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә компенсация түләүләре күләмнәре

| Бердәм тариф челтәренең хезмәт өчен түләү разрядлары | Компенсация түләүләре, сум |
|---|---|
| 1 | 3083 |
| 2 | 2983 |
| 3 | 2893 |
| 4 | 2782 |
| 5 | 2505 |
| 6 | 2480 |
| 7 | 2404 |
| 8 | 2392 |
| 9 | 2392 |
| 10 | 2380 |
| 11 | 2373 |
| 12 | 2373 |
| 13 | 2373 |
| 14 | 2373 |
| 15 | 2373 |
| 16 | 2373 |
| 17 | 2373 |
| 18 | 2373 |